ЮЛЫ БИЛГЕЛЕ

Рөстәм Миңнеханов Чечен Республикасына эшлекле сәфәр кылды

> 3

ЭЛЬМИРА ЗАКИРОВА:

«Миңа пионерия тормышында кайнау вәкаләте югарыдан ук тапшырылган булып чыкты бугай»

> 3

БАЛЫКЧЫ ФЛЕРА

Хатын-кызның балыкка йөрүе – гадәти хәл

> 4

КАДЕРЛЕ БӘРӘҢГЕ

Утыртасы да килә, ашыгырга да ярамый

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 68 (28841) | Чәршәмбе | 18 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

БДИ-2022

ТИЗРӘК ҺӘМ ЯХШЫРАК!

Быел бердәм дәүләт имтиханнарында укучыларга җәһәтрәк булырга туры киләчәк. Ни өчен дигәндә, тарих фәнен тапшыру вакытын – 55, җәмгыять белемен 25 минутка кыскартканнар. 2022 елда имтихан бирүчеләрне тагын нинди яңалыклар көтә?



Илдар Мөхәммәтҗанов

Республикада 11 нче сыйныфны 16 меңгә якын укучы тәмамлый. 2019 ел белән чагыштырганда, күпчелек фәннәрдән сынауларда катнашучылар саны кимегән. Ә менә информатиканы – 2814, инглиз телен – 2152, тарихны 1720 укучы сайлаган. Күбесе җәмгыять белеменә (6204), бик азлар француз теленә (15) өстенлек биргән. Быел да укучылар математикадан профиль һәм база өлешләрен сайлый ала. Андыйлар бер чама. Рус телен барлыгы 15879 укучы тапшырачак.

– Быел имтиханнарга яңа технологияләр кертелде. Узган ел бу тәҗрибәне өйрәндек. Элек Татарстан белем сыйфатын күзәтү үзәге иртәнге сәгать 4–5тә, имтиханнар башланганчы, биремнәр яздырылган дискларны таратып, аны имтихан пунктларында компьютер аша кәгазьгә күчерәләр иде. Дисклар ачылмаган очраклар да, ялгышлыклар да килеп чыккалады. Яңа технология эшне җиңеләйтәчәк һәм объективлыкны да арттырачак. Интернеттан биремнәрне алып, балалар күз алдында кәгазьгә бастырабыз. Эшләгән биремнәрне сканер аша чыгартып, кире шул үзәккә җибәрәчәкбез. Бу уңайлы булыр дип уйлыйм. Әлбәттә, моның өчен интернетның тизлеге яхшы булу кирәк. Бу җәһәттән Цифрлаштыру министрлыгы белән эш алып барабыз. Имтиханда биш минут та соңга калырга ярамый. Югыйсә кызыл зонага керәчәкбез, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин Татарстан Министрлар Кабинетында бердәм дәүләт имтиханнарына багышланган брифингта.

Укучылар арасында болай да, биремнәрне эшләргә вакыт җитмәде, дип әйтүчеләр очрый. Бер сәгатьләп вакытны киметкәч, укучылар өлгерерме соң? Өстәвенә бөтен фәннәрдән дә биремнәргә үзгәрешләр кертелгән, катгыйланган дип сөйлиләр. Илсур Һадиуллин аңлатканча, контроль үлчәм материалларын (КИМ) эшләүчеләр барысын да стандартларга туры китереп башкара. «Балалар да, әти-әниләр дә борчылмасын. Әгәр вакыт кыскартыла икән, димәк, биремнәр дә җиңелрәк булыр», – дип тынычландырды министр.

Имтиханнарда төп үзгәрешләрнең берсе контроль үлчәм материалларында чагыла. Укучылар алган белемнәрен тормышта куллана белүен күрсәтергә тиеш. Биремнәр функциональ белемне арттыруга юнәлдерелгән. Дөресрәге, чит ил тикшеренүләренә нигезләнеп эшләнгән. Әгәр безнең укучылар биремнәрне үтәп, яхшы нәтиҗәләргә ирешә икән, егет-кызлар илнең мәгарифен дөньякүләм унлыкка кертә ала дигән сүз.

Күптән түгел игълан ителгән белем сыйфаты исемлегендә Татарстан күрсәткечләре мактанырлык түгел. Компьютердан файдалану буенча ахыргы урында дигән тәнкыйтькә дә министр ачыклык кертте:

– Информатикага килгәндә, матбугат чаралары Татарстан нибары 44 нче урында дип язып чыктылар. Беренчедән, бу урын түгел. Икенчедән, балаларның компьютер куллануын аңлатмый. Без – яшел зонада. Чагыштырып әйтү дөрес түгел. 2019 елда 9 нчы сыйныф, узган ел 11 нче сыйныф укучыларының информатикадан имтихан нәтиҗәләре исәпкә алынган. Беренчедән, тәмамлаучыларның саннары арасында аерма зур. Монда каршылыклы фикерләр җитәрлек. Безнең максат 36 мең баланың барысыннан да информатиканы сайлату түгел. Химия, математика һәм башка профильләребез дә бар. Аннан алар виртуаль дөньяга китәчәк, ул ягы да бар. Бик четерекле мәсьәлә. Без башкарган эшләр барысы да дөрес. Мәктәпләрдә компьютерлар җитә.

Министр имтиханнарны уздыруда кәгазь кытлыгы юк, әти-әниләрдән моның өчен акча җыю булмаячак, дип ышандырды. Имтиханнарны уздыру чыгымнары 40 миллион сумга төшә. Монда кәгазь дә, сканерлар һәм башкасы да керә.

– Укучылар имтиханнарны яхшы бирер дип ышанабыз. Әмма берникадәр сагаю да бар. Быелгы 11 нче сыйныф укучыларына тугызны тәмамлаганда имтихан бирергә туры килмәде. Әмма алар өчен сынау имтиханнары үткәрелде. Психологик яктан әзерләнделәр, – диде министр.

Донецк һәм Луганск Республикаларыннан килгән балалар темасы да читтә калмады. Әлеге 19 укучыга имтиханнарны тапшыру өчен барлык шартлар тудырылачак. Әмма таләпләр бертөрле булачак. Имтиханнар вакыты, процедурасы – берни үзгәртелми.

Киләсе елдан БДИны бетерәләр дигән сүзләргә карата да министр үз фикерен әйтте.

– Имеш-мимешләр күп. Хәзерге вакытта БДИ – укучыларның белемен тикшерә торган бердәнбер бәйсез форма. Нинди үзгәрешләр булачагын әйтә алмыйм. Без әлегә балаларны сынауларга әзерлибез һәм аларга уңышлар теләп калабыз. Алдагысын вакыт күрсәтер. Мин нәрсәдер үзгәрер дип уйламыйм, – диде Илсур Һадиуллин.

Чистарыну дәвам итә

Чистарту-җыештыру икеайлыгының ай ярымы эчендә экологик кагыйдәләрне бозуның 3904 очрагы ачыкланган, 1726 беркетмә төзелгән, барлыгы 3,902 миллион сумлык штраф салынган. Тиешсез урыннарда 2411 чүплек табылган, 1923е (79,8%) юк ителгән. Икеайлык башланганнан бирле җәмгысы 396 мең куб. м чамасы чүп-чар җыеп озатылган. Җыештыру эшләренә барлыгы 523 меңнән артыграк кеше һәм 12 мең берәмлек махсус техника җәлеп ителгән, 229 меңнән күбрәк агач-куак утыртылган. Автомобиль юллары кырыйларын чистарту өчен һәр көн саен 614 кеше һәм 210 берәмлек махсус техника чыга.

Республика иҗтимагый экологик кабул итү бүлмәсенә һәр көн саен төрле элемтә каналлары аша мөрәҗәгатьләр керә. 11 майга китерелгән мәгълүматлар буенча, барлыгы 2867 мөрәҗәгать алынган инде.

Тикшерүләр 11 тапкыр кимегән

Мораторий кертүнең ике ае эчендә предприятиеләрне тикшерү гыйнвар – февраль айларындагыга караганда 11 тапкыр кимегән. Шул ук вакытта мораторий кертү көненнән – 10 марттан аны бозуга шикаятьләр булмаган. Бу хакта Татарстан Премьер-министры урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов белдергән. Биредә сүз бизнеска планлы тикшерүләр үткәрүне туктатып тору турында бара. Тикшерүләр ябык исемлеккә кертелгән кайбер объектларга карата гына сакланып калган. Шулай итеп, Татарстанда мораторий кертелгәннән бирле барлыгы 2211 тикшерү гамәлдән алынган, 512се туктатылган.

Һава торышы рекордлары

Республикада моннан бер ел элегрәк 1898 елгы рекорд челпәрәмә килде. 2021 елның 17 маенда һава температурасы +33,4 градуска җитте. Шул ук вакытта бер гасырдан күбрәк вакыт элегрәк термометрның терекөмеш баганасы +30,8 градус күрсәткән. Хәер, узган елда 17 майда гына түгел, 14 һәм 15 май көннәрендә дә рекордлар яңарды: 30 градустан артык эссе булды. Һава температурасы гына түгел, явым-төшемнең – аз, атмосфера басымының зур булуы буенча да рекордлар теркәлде.

Быел исә май җылы көннәре белән бик үк сөендерми әле. Ай башында төнлә һава температурасы –7 градуска кадәр төште. Көчле җил, яшеннәр булгалады, боз яуды.

КФУ профессоры Юрий Переведенцев әйтүенчә, май аенда уртача температураның +13 градус чамасы тәшкил итүе көтелә. Көндез җылытса да, төннәрен салкын. Мәсәлән, ял көннәрендә – 20 һәм 21 майда – республикада кырау көтелә. Синоптиклар фаразына караганда, Татарстанның кайбер районнарында –1 градуска кадәр суытырга мөмкин.

Урман хуҗалыгы

Урманчы бәхете – яңгыр

Кызу көннәрне яратмый алар. Урманчылар өчен яңгыр сибәләп торган көннән дә яхшысы юк. Бердән, урман үссен өчен су кирәк, икенчедән, янгын булмый кала. Татарстан урманчылары янгынга әзерме?

Кичә бер төркем журналистлар Биектау районында урнашкан Урман янгыннарын сүндерү үзәгендә булды. Ут чыга калса, үзләренең әзерлеген, нинди очракта кайсы техниканы эшкә җигәселәрен күрсәтте урманчылар.

– Мондый күнегүләр комачау итми, – ди Урман янгыннарын сүндерү үзәге җитәкчесе Айдар Гайфуллин. – Ел саен урманчылыкларда янгынга каршы тору өчен кирәкле техника, җиһазлар яңартылып тора. Әлеге эшләр «Урманнарны саклау», «Экология» илкүләм проектлары кысаларында башкарыла. Безнең үзәктә тәүлек буе кизү торучы төбәк диспетчерлык хезмәте эшли. Үлән януга, анда хәбәр килә. Аннары инде диспетчерлар, януның кайсы җирдә булуына карап, йә җирлек башлыгына, йә урманчылык җитәкчелегенә хәбәр бирә.

Узган ел 26 урман янгыны теркәлгән. Шуның 19ы урман фонды җирләренә зыян салган. Шөкер, быел әлегә янгыннар күзәтелмәгән. Урманчылар әлеге дә баягы һава торышына рәхмәтле.

– Май бәйрәмнәре салкынча һәм яңгырлы булу аркасында, урманга барып ял итүчеләр булмады. Республикада кертелгән янгынга каршы махсус режим да үз эшен эшләде. Урман янәшәсендә яшәүчеләр генә түгел, башкалар да учак ягу, шашлык пешерүдән тыелып торды, – ди Айдар Гайфуллин.

Былтыргы янгыннарны искә төшерик. Урман яну очракларының күбесе республиканың көньяк-көнчыгышында күзәтелде. Иң зур янгын очрагы Әлмәт, Лениногорск районнарында теркәлгән. Нилектән урманнар яна соң? Без бу сорауны Айдар Гайфуллинга да бирдек. Аның фикеренчә, нинди генә янгын булмасын, анда кешенең гаебе зур.

– Үлән яну, урманга ут кабу кебек очракларның 90 процентында кеше гаепле. Без күпме генә кисәтеп торсак та, учагын да ягалар, үләнгә ут та төртәләр. Төрле кеше бар, әмма артыннан җыештырмыйча, учагын сүндермичә китүчеләр шактый очрый. Урман эчендә чүп-чарның күп булуы да янгын куркынычы тудыра. Кояшта кызып яткан пыяладан да ут кабарга мөмкин бит, – ди ул.

Республикада янгынга каршы тору өчен мөмкинлекләр зур, дибез. Нигә соң узган ел урманнар янды? Әнә шул сорауга да җавап эзләдек. Урманчылар, былтыр яз иртә килде һәм эссе булды, дип аңлата. Алар әйтүенчә, элек урман эчләреннән, басулардан, кырлардан халык печән чабып ала торган була. Хәзер маллар киму сәбәпле, печән бераүгә дә кирәкми. Ә корыган печән ут чыгуга бер сәбәп булып тора. Урманчылар тагын бер сәбәпне әйтә. Баксаң, көчле җил-давыл вакытында электр чыбыклары өзелеп төшеп тә янгын чыга икән. Көньяк-көнчыгыш районнарда урманнарның биеклектә урнашулары аркасында ут чыга. Өстәрәк урнашкан саен, ут тиз тарала, ди алар.

Ахыры 2 нче биттә >

САН

Урманнарда янгын куркынычы 15 октябрьгә кадәр саклана. 2022 елда Татарстанда коры үләнгә ут кабуның 229 очрагы теркәлгән. Урманчылар, янгын хакында хәбәр алуга, 3 сәгать эчендә бу урынга килеп җитәргә тиеш. Аларга янгынны бөтенләй сүндерү өчен бер тәүлек вакыт бирелә.

Сүзгә-сүз

rg.ru

Сергей ЛАВРОВ, Россиянең тышкы эшләр министры:

Россия интернетсез калмаячак. Президент Владимир Путин формалаштырган әлеге бурычлар үтәләчәк. Ышаныгыз: сез дә, шул исәптән мин дә интернетсыз калмаячакбыз.

(«Яңа горизонтлар» мәгариф марафонынннан)

РОССИЯДӘ – АКЧАНЫ САК ТОТУ

«Зарплата.ру» хезмәте үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, илдә яшәүчеләр акчаны янга калдыру ягын кайгырта башлаган. Бу язда Россиядә яшәүчеләрнең 80 проценты чыгымнарын чикләргә тотынган.

44%.......акчаны бар өлкәдә чиклим
13%........ял
12%........кафе-рестораннар
9%.........азык-төлек
7%.........матурлык салоны
3%.........техника
2%.........ремонт эшләре
1%..........хәмер

Кредитка алучылар арткан

Апрель аенда Татарстанда барлыгы 947 автокредит бирелгән. Алдагы айдагыга (686) караганда 38 процентка күбрәк бу. Гомумән, Татарстан узган айда рәсмиләштерелгән автокредитлар саны ягыннан иң күп кредит алган 30 төбәк арасында 4 нче урынга чыккан. Республиканы Мәскәү (1546), Мәскәү өлкәсе (1351) һәм Санкт-Петербург (1068) кына узган. Башкортстан (880) бишенче урынны алган. Кредит тарихлары бюросы белгече Алексей Волков әйтүенчә, автокредитларга бәйле бүгенге вазгыять 2020 елның «карантинлы» апрель – май айларын хәтерләтә. Санкция һәм ставкалар шогыннан бераз айныганнан соң бу өлкәдә берникадәр җанлану сизелә.

Мартка килсәк, республикада бу айда бирелгән автокредит күләме февральдәгегә караганда 79,4 процентка кимрәк булган. Аның уртача күләме 1140642 сум тәшкил иткән. Февраль аендагы белән чагыштырганда, ул 1,6 процентка азайган.

dreamstime.com



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БОДАЙ «ЯЗ»ГА КИТЕРЕРМЕ?

Канда адреналинны арттырыйм дисәң, хәзер трамплиннан сикереп мәшәкатьләнәсе юк, яңалыклар тасмасын карап чыгу да җитә.

2020 елның җәеннән бирле ике дәүләт түнтәрелешен кичергән Мали чираттагы хәрби фетнә белән сыналды. Армия офицерлары һәм унтер-офицерлары төркеме оештырган түнтәрелеш 11 майдан 12 майга каршы төндә үк булган инде, әмма уңышсыз төгәлләнгән фетнә турында мәгълүмат яңа гына чыкты. Якын киләчәктә Җир шарында фетнәләр ешлыгы һәм тыгызлыгы артыр шикелле, чөнки дөньякүләм азык-төлек кытлыгы оешып ята. Бердән, 2022 ел уңышы планета масштабында түбәнрәк булыр дип фаразлана. АКШның Авыл хуҗалыгы министрлыгы соңгы дүрт елда беренче тапкыр бодай уңышы глобаль рәвештә кимрәк булыр дигән рәсми фаразын игълан итте инде. Украина уңышны үткән елгыдан 35 процентка кимрәк җыяр дип көтәләр. Кытай, Франция, Австралия, Аргентина, Һиндстан ашлык сугуны киметерләр дип фаразлана. Һиндстан гадәттән тыш эсселек һәм корылыктан газап чигә. Чәчелгән ашлык масштаблы рәвештә янды-көйде инде. АКШның күпчелек территориясендә дә хәзер үк июль температурасы урнашты, 35 градустан югарырак дигән хәбәрләр килә. Шуңа карамастан, ил ашлык уңышын арттырыр дигән өмет бар. Тагын Канада һәм Россия зур уңыш җыеп алырга вәгъдә итәләр. Без яшәгән ил рекордлы уңышка исәп тота. Әлбәттә, бу өч ил генә глобаль ашлык кытлыгын каплый алмаячак. Санкцияләрнең Россиядән ашлык сатуны кыенлаштырачагын да исәпкә алырга кирәк. Глобаль ашлама дефицитының да Россия һәм Беларуська кертелгән санкцияләр нәтиҗәсе булуын истә тотыйк. Шул фонда АКШта тарихта беренче тапкыр тиресне биржада фьючерслар белән сата башладылар. Беренче фьючерс контрактлары төзелде инде.

Вазгыять ашлыкка бәяләрнең шартлаулы күтәрелешен хәзер үк китереп чыгарды. Инфляция болай да югары. Җир шарында ике миллиардтан артык кеше ике урынлы санлы инфляциядән интегә, диләр. Үткән җомгада Һиндстан хөкүмәте бодай экспортын тыйды. Нәтиҗәдә халыкара базарда бодайга бәяләр рекордлы рәвештә үсте, 2010–2011 елларда «гарәп язы»н китереп чыгарган дәрәҗәгә җитте. Әлегә азык-төлек бәяләренең берничә тапкыр үсеше нәтиҗәсендә бары тик Иранда гына берникадәр чуалышлар булып алды.

Азык-төлек инфляциясенә энергия чыганакларына күтәрелгән бәяләр дә килеп кушылып, дөньяның бай илләрендәге халыкларны да фәкыйрьләндерә. Мәртәбәле яңалыклар агентлыклары, 250 мең британ гаиләсе, ягулык бәяләренең рекордлы үсеше нәтиҗәсендә, хәерчелек чигендә яшәячәк дигән фараз бирделәр. Икътисад һәм социаль тикшеренүләр милли институты NIESR бер миллионнан артык британлының гадәттән тыш фәкыйрьлектә көн күрәчәген фаразлый.

Россиядә

«МОСКВИЧ»НЫ КАРШЫЛАП

Россия икътисадында санкцияләргә бәйле рәвештә мәйданга гаҗәп хәлләр чыга. Илне бөлдерергә тиешле санкцияләр экспорт табышын гадәттән тыш арттыралар. Март аенда Германиянең Россиядән товар сатып алуы акчалата күләмдә 77,7 процентка арткан. Илне нигездә энергия чыганакларына күтәрелгән бәяләр баета. Россия коксын һәм нефть продуктларын чит илләргә сату акчалата керемне 203,5 процентка күтәргән. Әмма акчаның күплеге муллык вәгъдә итми. Статистика чыккач, импортның апрель саннары 70 процентка кимрәк булуын белербез дип көтелә. Импортны арттыру өчен, федераль хөкүмәткә моңарчы күрелмәгән адымнар ясарга туры килә. «Параллель импорт» дигән сәүдә ысулы рөхсәт ителде һәм рәсмиләштерелде инде. Хәзер хөкүмәт бу тишектән контрафакт товарлар агылып килеп кермәсен өчен тырышлык куя. Импорт товарларга пошлиналарны бетерү дә күз алдында тотыла. Сум курсының үсүе һәм пошлинасыз сәүдә чит ил товарларына бәяләрне төшерергә тиеш ул үзе, әмма әлегә бәяләрнең кискен түбәнгә сикерүе күзәтелми. Безне кытлыктан коткара торган бердәнбер чара ул – бәяләрнең түшәмне узган күтәрелеше, шуңа күрә якын киләчәктә очсыз бәяләр «куркынычы» янамас дип уйлыйк.

Чит ил брендларының Россияне ташлап китүе дәвам итә. Импортның кимүенә үзебездә чит ил бизнесы тарафыннан җитештерелгән товарларның юкка чыгуы да килеп өстәлә. Март ахырында «Рено» бренды (Renault) Россияне ташлаячагы хакында игълан иткән иде. Безнең базарга бик күп автомобиль брендлары арты белән борылды. General Motors, Mercedes-Benz, BMW, Ford, Land Rover, Toyota, Audi һәм Mazdaлар үз автомобильләрен сатуны туктаттылар, BMW, Hyundai, Renault һәм Skoda Auto Россиядәге конвейерларына йозак элде, Volkswagen җитештерүне дә туктатты, безгә үз продукциясен озатудан да баш тартты. Илдә автомобиль җитештерү бик нык кими. Бу кытлык кына түгел, эшсезлек тә вәгъдә итә.

Мәскәү мэры Собянин әфәнде Renaultның башкаладагы заводында онытылган «Москвич» брендын кире кайтарырга вәгъдә итә. Онытылган дигәч тә, хәзерге яшьләр белми, без, совет «могикан»нары, «Москвич»ны онытмадык әле. 1987 елда совет тарихында беренче тапкыр ул автомобильне чиратсыз сата башлаганнар иде. Дөрес, андый иркенлек озак бармады. Оекбашларга кадәр дефицитка әверелә башлагач, «Москвич»ны булса да алып калмавына үкенгән совет кешеләре байтак булды. Брендның дәрәҗәсен менә шул күрсәтә дә инде: автомобильгә сусаган һәм коргаксыган совет кешеләре дә аны алырга ашыгып китмәгәннәр. Ул машинаны кабызу бик кыен булуы истә калган. Renault калдырып киткән конвейерлардан «Москвич» исеме астында шул совет чишелешендәге автомобильләр төшәрме, әллә мәсьәләнең яңа технологик юлын табарлармы – әлегә ачык мәгълүм түгел. Киләчәктә легендар «Москвич»ның электромобильгә әйләнүе генә күздә тотыла. Хыяллар тормышка аша, диләр бит. Совет чорын сагынучыларның үткәннәргә кайту теләге «Москвич» образында чынбарлыкка әйләнеп бара.

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ЮЛЫ БИЛГЕЛЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Чечен Республикасына эшлекле сәфәр кылды. Грозныйда узган очрашуда ике арадагы хезмәттәшлекне үстерү турында сөйләштеләр. Сәфәр барышында республиканың беренче президентын да искә алдылар.

Рөстәм Миңнеханов иң беренче эш итеп Чечен Республикасының беренче президенты, Россия Герое Әхмәт Кадыйровның каберенә барды, аның рухына дога кылды.

Грозныйда республика башлыгы Рамзан Кадыйров белән очрашуда ике республика арасында хезмәттәшлек юллары да барланды. Рөстәм Миңнеханов Татарстанның бирегә күбрәк «КамАЗ» машиналары, машина төзелеше продукциясе җибәрергә, сәнәгать, төзелеш материаллары тармагында, югары технологияле медицина җиһазлары кайтаруда хезмәттәшлекне арттырырга әзер булуын искәртте. Белем бирү, сәламәтлек саклау, спорт, туризм һәм мәдәният тармакларында да хезмәттәшлекне үстерү өчен мөмкинлекләр зур.

Рөстәм Миңнеханов, төбәктәге татарларга теләктәшлек күрсәткән өчен Чечен Республикасы җитәкчелегенә рәхмәт сүзләре дә җиткерде. Очрашу азагында Рөстәм Миңнеханов белән Рамзан Кадыйров Татарстан һәм Чечен республикалары арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешүне тормышка ашыру чаралары планын имзаладылар. Әлеге документ моннан 20 ел элек ике республика арасында имзаланган килешү кысасында уртак эш өчен «юл картасы» булачак.

Быел Чечен Республикасы үзенең 100 еллыгын бәйрәм итә. Рөстәм Миңнеханов шул уңайдан котлау сүзләрен җиткерде. Билгеле булганча, әле узган атнада гына Казанда Чечен Республикасы мәдәнияте көннәре узды. Татарстан башкаласында республиканың мәдәният министры Айшат Кадыйрова җитәкчелегендә делегация булып китте.

tatarstan.ru

Эш сәфәре барышында Рөстәм Миңнеханов «Россиянең иң яхшы такси йөртүчесе-2021» бәйгесенең федераль этабы ачылышында да катнашты. Дүртенче ел рәттән уздырылучы әлеге бәйге 18 майга кадәр дәвам итәчәк. Ул «Грозный крепосте» автодромында уза.

– Бу – бик заманча автодром. Элеккеге автоузышчы буларак, мин аны шундук аңладым. Әйе, такси йөртүчеләр – дөрестән дә, шәһәрдәге юл хәрәкәтенең иң төп катнашучылары. Хәрәкәтне дөрес оештырып, пассажирларның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә кирәк. Такси йөртүче машинаны оста иярли белсен. Бу бәйгенең югары дәрәҗәдә узачагына ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Авылны булдыклылар яшәтә

Республикада авылда яшәүчеләрнең эшмәкәрлек активлыгын үстерү буенча зона киңәшмәләре дәвам итә. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кичә Кукмарада республиканың төньяк зонасына керүче 11 муниципаль районның хакимият башлыклары, башкарма комитетлар, авыл җирлекләре һәм фермер хуҗалыклары җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрде.

Фәрит Мөхәммәтшин Кукмара җиренә аяк басуга, Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров, район хакимияте башлыгы Сергей Димитриев һәм Дәүләт Советы депутатлары белән Чура авылында «Монокорм» сөтчелек комплексында булды. Комплекс терлекчелек буенча махсуслашуның яңа формаларыннан берсе булып тора. Ул 144 савым сыеры асрауга исәпләнгән. Бозаулар башка фермада үстерелә.

Киңәшмәдә катнашучылар район мәдәният йорты фойесында Кукмара предприятиеләре һәм оешмаларының продукциясе күргәзмәсе белән танышты. «Кукмара сөте», «Кукмара икмәге», «КукморЗерноторг» кебек фирмалар вәкилләре парламент җитәкчесенә авылда кече бизнеска дәүләт ярдәменең мөһимлеге һәм җитештерүне үстерү өчен уңайлы шартлар турында сөйләде.

Дәүләт Советы Рәисе, зона киңәшмәсен ачып, Татарстан Президентының авылда эшмәкәрлекне һәм социаль активлыкны үстерү буенча куйган бурычларының бүгенге катлаулы вазгыятьтә аерым бер әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте. «Хакимиятнең барлык органнары һәм оешмаларның бергә эшләве өчен икътисадны тотрыклы үстерү буенча план кабул ителде, Оператив штаб булдырылды, – диде ул. – Беренче чиратта безгә халыкны иң кирәкле товарлар белән тәэмин итәргә, мәшгульлекне саклап калырга, төп предприятиеләрнең өзлексез эшләвенә ирешергә һәм бизнеска яңа шартларга җайлашуга ярдәм итәргә кирәк. Башлангыч этапта логистика системаларын үзгәртеп кору һәм продуктлар, дарулар, беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итүдәге өзеклекләрне юкка чыгару төп бурыч булса, хәзер без бәяләрнең нигезсез үсүенә юл куймаска тиеш. Әлбәттә, бу вазгыятьтә азык-төлек мәсьәләсенә аерым зур игътибар бирелә. Әйтергә кирәк, Татарстан терлекчелек продукциясе белән үзен тулысынча тәэмин итә. Проблемалар да бар, әлбәттә, сез аларның барысын да белеп торасыз. Шуларның берсе – терлекләрнең баш саны кимү».

Парламент башлыгы фикеренчә, республикада кече хуҗалыкларны үстерүгә зур игътибар бирелә. «Бүген кече хуҗалыклар – 470 меңнән артыграк шәхси ярдәмче хуҗалык, 4 меңнән күбрәк фермер хуҗалыгы һәм 300дән күбрәк куллану кооперативы ул, – дип искәртте Фәрит Мөхәммәтшин. – Ел саен кече хуҗалыкларга ярдәм итүгә грантлар һәм субсидияләр рәвешендә 2 миллиард сумнан артыграк акча бүлеп бирелә. Быел агросәнәгать комплексына ярдәм итүгә тулаем 13,2 (узган елдагыга карата үсеш – 106,5%) миллиард сум җибәрү күздә тотыла. Федераль үзәк катнашында барлыгы 5,3 миллиард сумлык 28 чара тормышка ашырылачак. Шулардан 3,8 миллиард сумы (71,7%) – федераль бюджет хисабына, 1,5 миллиард сумы (28,3%) – республика бюджеты хисабына. «Авыл территорияләрен комплеслы үстерү» дәүләт программасын финанслауга 1,5 миллиард сум күздә тотылган. Бу республиканың 34 районында 5 мең кв. м торак, 84 объект төзү, челтәрләр һәм корылмаларны капиталь төзекләндерү мөмкинлеге бирәчәк. Агымдагы елга «Агростартап» программасы кысасында 160,4 миллион сум бүлеп бирелгән. Узган елда 60 җиңүче үз проектларын гамәлгә ашыруга 161 миллион сум алды. Нәтиҗәдә сыерлар санын – 1840ка, атларны – 840, кош-кортларныкын 540 меңгә җиткерү көтелә.

Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчеләр, белгечләр һәм фермерларны гамәлдәге барлык грант программаларында активрак катнашырга өндәп, авылны саклап калуның, аны социаль һәм икътисади яктан үстерүнең салада яшәүчеләрнең активлыгына аерылгысыз бәйле булуын басым ясап әйтте. Ул район хакимиятләре башлыкларына, кызыксынулы барлык кешеләрне чакырып, үз районнарында очрашулар үткәрергә тәкъдим итте. «Мондый очрашуларга министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләрен чакырыгыз. Кешеләр барлык ярдәм чаралары турында белеп торырга тиеш. Авылда актив, булдыклы кешеләр булганда гына, дәүләт ярдәме нәтиҗәлегә әйләнәчәк», – диде ул.

СЕЗ – БЕЗНЕҢ ИҢ ТӨП ТАЯНЫЧЫБЫЗ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Татарстан Республикасы Матбугат көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле массакүләм мәгълүмат чаралары, матбугат һәм полиграфия тармагы хезмәткәрләре һәм ветераннары! Сезне һөнәри бәйрәмегез – Татарстан Республикасы Матбугат көне белән ихлас күңелдән котлыйм.

Бу бәйрәм көнендә без республиканың мәгълүмати йөзен булдыруда армый-талмый тырышкан һәркемнең хезмәтен хөрмәтлибез. Үзенчәлекле һәм бай тарихлы журналист, репортер, корреспондент һөнәре җәмгыять өчен һәрвакыт кирәк һәм гаять әһәмиятле булды. Нәкъ менә шуңа күрә Татарстанның гавами хакимият органнары, ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнеп, озак еллар дәвамында барлык массакүләм мәгълүмат чаралары белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итә.

Хәзерге вакытта глобальләшү, яңа мәгълүмат технологияләрен үстерү чорында республика журналистикасы үз офыкларын киңәйтүне дәвам итә. Буыннан-буынга күчеп килгән бәһаләп бетергесез тәҗрибә һәм иң яхшы традицияләрнең дәвамчанлыгы каләм әһелләренең һөнәри осталыгын көннән-көн арттыра. Тирәнтен аналитик мәкаләләр, күңел ачу, фәнни һәм танып белү тапшырулары, мәдәни-агарту, балалар өчен программалар – Татарстанның һәр массакүләм мәгълүмат чарасының рәхмәтле үз укучысы, караучысы, тыңлаучысы бар…

Сезнең кулыгызда куәтле идеологик корал, аның ярдәмендә юнәлешләр билгеләнә, дөньяга караш булдырыла, үсеп килүче буыныбызга идеаллар һәм кыйммәтләр тапшырыла. Сезнең һәрберегезнең дә мәгълүмат кырында рейтинг һәм матур сурәт өчен эшләвегезгә түгел, ә объектив чынбарлыкны ачык һәм гадел, һәрьяктан үлчәп һәм җаваплылык тоеп чагылдыруыгызга ышанабыз. Совет шагыйре В.В. Маяковский сүзләренчә, сүз – кешелек көченең гаскәр башлыгы. Россия Федерациясендәге бүгенге вазгыятьне игътибарга алып, төрле ялганга, фейкларга һәм ачыктан-ачык провокацияләргә каршы тору аеруча әһәмиятле булып тора. Һәм шушы глобаль мәгълүмати каршылыкта сез – безнең иң төп таянычыбыз.

Сезгә сайланган һөнәрегезгә тугрылык һәм республика хакына күпкырлы хезмәтегез өчен рәхмәтемне белдерәм! Бәйрәм көнендә сезнең барыгызга да исәнлек-саулык, бәхет, тынычлык, бетмәс-төкәнмәс иҗади куәт һәм эшегездә, тормышыгызда зур уңышлар телим!

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы рәисе урынбасары, эчке хезмәт полковнигы **Рябов** Андрей Александрович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр хуҗалыгы көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Бакаев** Җәмил Гаделҗан улы; республиканың юл-транспорт төзелешенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ПРИС Меткон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең фәнни консультанты **Брехман** Александр Иосифович; халыкны социаль яклау системасын камилләштерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары **Бутаева** Наталья Владимировна; театр сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты, әйдәүче сәхнә остасы **Вәлиев** Камил Мөхәммәтшакир улы; халык сәламәтлеген саклау эшенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең психотерапия һәм наркология кафедрасы мөдире **Карпов** Анатолий Михайлович; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Заиковский» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Фәттахов** Радик Шәрип улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

УРМАНЧЫ БӘХЕТЕ – ЯҢГЫР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Урманчылар журналистларга, урманда янгын булган очракта, ничек эшләгәннәрен күрсәттеләр. Диспетчерлык үзәгеннән хәбәр алуга, алар юлга чыга. Янгын сүндерү машиналары әзер. Янгынның тиз сүнүендә машина йөртүченең дә роле зур. Биектауда исә бар гомерен урман эшенә багышлаган Габбас Галәветдиновны яшьләргә үрнәк итеп куялар.

– Мин күптән пенсиядә инде. Әмма эшемне ярату тик утыртмый. Хәл булганда эшләргә исәп. Язгы-җәйге чорда урманнарны саклау бездән тора. Кызулар булганда, янгын куркынычы артканда, тәүлек буе кизү торабыз, – ди ул.

Өйрәнүләр вакытында да тизлек Габбас абыйдан торды. Ул өйрәнеп беткән инде, эшләгәнен күзәтеп торганда, күзләр камаша. Тиз арада шлангын да әзерләп куя, суын да сиптерә. Әйтүләренчә, су да җитә, машиналар да төзек, янгын сүндерүчеләр дә бар. Әмма теләкләре бер: урманга ут кермәсен иде!

Моның өчен нишләргә соң? Айдар Гайфуллин әйтүенчә, республиканың төрле районнарында 25 урман янгынын сүндерү станциясе бар, минеральләштерелгән полосалар ясалган. Урманнар гел күзәтү астында. Җәяү йөрүчеләр дә, күктән күзәтүчеләр дә бар. Урманчылар халыктан чүпләрен урманга ташламауларын сорый. Урман янәшәсендә яшәүчеләр исә үз территориясен кайгыртырга тиеш. Урманга ут кертмәү – алар өстендә. Моның өчен ике арага чокырлар казып куярга кушалар.

Быелдан тагын бер яңалык – фермер хуҗалыклары басуында ут чыга икән, андыйларны дәүләттән бирелүче субсидиядән мәхрүм итмәкчеләр. Әнә шулай итеп, урманнарны янгыннан сакларга тырышалар. Шулай ук урманда янгын куркынычсызлыгын бозучыларны штраф көтә. Аның күләме гади кешеләргә – 3 мең, вазыйфаи затларга – 20, юридик затларга 200 мең сумны тәшкил итә.

Сүз уңаеннан, республикада «Татарстанның чиста урманнары» акциясе дәвам итә. Аның максаты – урманны чүп-чардан арындырып, янгыннарга юл куймау. Быел акция 18 апрельдә башланып китте һәм ул 18 июньгә кадәр дәвам итәчәк. Узган шимбәдә республика урманнарыннан 2,2 мең куб. м каты көнкүреш калдыклары җыелган, 2,8 мең куб. м күләмендә коры-сары һәм агачлар черү өчен өемнәргә өеп куелган. Акциядә 25 мең кеше катнашкан.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Автор фотосы

ЧАКЫРА ПИОНЕР БЫРГЫСЫ

Бу көннәрдә илебездә Бөтенсоюз пионер оешмасы төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтәләр. Күпләребез өчен бу көн, якты матур хатирәләр, күңелле балачак еллары булып, сагындырып искә төшә. Һәм һәркайсыбызда моңа кагылышлы бихисап истәлекләр саклана.

Минем өчен мәктәпнең пионервожатые идеал булып тоела иде. Чөнки ул бии дә, җырлый да, походларга да алып чыгып китә, кыен хәлләрдән чыгу юлын да белә, синең өчен дус һәм сердәш тә. Иң күп белүче, иң ягымлы, иң әйбәт кеше иде ул вожатый апа!

Мәктәптә пионер-комсомол эшләрендә кайнап, интернациональ дуслык клублары оештырып, күрше Башкортстан пионерлары белән дуслык учаклары кабызып, «Взвейтесь кострами, синие ночи»ларны җырлап, тимурчылар командасы белән әби-бабайларга булышып, «Аҗаган» хәрби спорт уеннарында катнашып, үзебез башлап җибәргән җыелма отрядлар эше турында «Яшь ленинчы»га, «Ялкын»га мәкаләләр язып, «Яшь хәбәрче» таныклыклары алып, тынгысыз да, рәхәт тә тормышта үстек без.

Ә миңа пионерия тормышында кайнау вәкаләте югарыдан ук тапшырылган булып чыкты бугай. Университетта укыганда, 3 нче курстан соң пионер лагеренда педпрактика үтәргә тиеш идек. Актаныш районы Пионерлар йорты директоры, чын пионер хәрәкәте ветераны Дәлия апа Ханнанова сөенеп каршы алды мине, «Акчарлак» район пионер лагерена вожатый итеп билгеләп тә куйды. Агыйдел буендагы ул лагеребыз, палаткалардагы күңелле тормышыбыз, узып киткән теплоходларны быргы кычкыртып сәламләүләребез, аларның гудок биреп узуларына куануларыбыз, соңыннан отрядымдагы малайлар-кызлар белән хатлар алышулар... Барысы да романтикага, хыялга төренгән иде. Казанга килгәч, фотосалонда пионервожатый формасыннан фотога төшеп, отрядым пионерларына җибәреп йөрүләрем дә шул дөньяны, балаларны яратудан булгандыр.

Бу язма шәхси тоелса да, анда ил тарихы, җәмгыятьтәге үзгәрешләр чагылмый калмый барыбер. Хәзер менә искә төшерәм дә... Пионерия тормышына бәйле эш, чынлап та, язмышыма язылган булган, ахрысы. Университетның соңгы курсында укыганда республикабызның пионер журналы «Ялкын»га эшкә чакырдылар. Һәм анда да әле пионер тормышы бүлеге редакторы вазыйфаларын тапшырдылар! Командировкалы, летучкалы, «Артек»лы, марш-маршрутлы, слетлы, галстуклы, пионер учаклы редакция тормышы башланды. Мәктәпләргә баргач, Муса Җәлилнең беренче редакторыбыз булганын, Абдулла Алишның журналда җаваплы секретарь булып эшләгәнен, аның редакциядә хәтта пионер галстугыннан йөргәнен горурланып сөйли идек. Ул елларда радиодан балалар өчен тапшыруларда бик еш яңгырый торган «Пионер ялкыны» дигән җырның сүзләрен исә «Ялкын»да җаваплы секретарь булып эшләгән Разил абый Вәлиев язган иде! «Җәлилләр, Алишлар ялкыны/Мәңгелек ут булып балкыды...» – дип, ничәмә буын җырлады! Ә журналның 60 еллыгына әзерләнгәндә баш редактор Роза апа Хафизова мине Мәскәүгә командировкага махсус җибәрде. Муса Җәлилнең хатыны Әминә апа, кызы Чулпан, оныгы Таня белән очрашып, материал язарга! Соңыннан Җәлилнең оныгы Таня исеменнән «Чәчәкләр китерәм бабама» дигән язма журнал битләрендә урын алды.

Кайларда гына булмыйсың, кемнәр белән генә очрашмыйсың! Кылт итеп, «кукурузник»та Чирмешәнгә очуым искә төште. Чирмешән районы Бәркәтә мәктәбеннән дружина советы председателе Миләүшә Миргалимова хаты безне тетрәндерде. Галстугым, форма күлмәгем, пионер слетына чакыруым калды, дип, янып торган өйгә кереп һәлак булган Мәдинә исемле кыз турында иде ул. Тиз генә юлга җыендым. Тирән, үтемле язма килеп чыкты. Ул чактагы баш редакторыбыз Роза Туфитуллова язмага исемне үзе куйды. «Янган галстук, яки Батырлык турында» дип атала иде ул. Хәзер инде ул вакыйгаларга башкача бәя биреп утырам. Идеяләр өчен үзеңне корбан итү кирәк иде микән? Хәер, ул бала аны ул дәрәҗәдә үк аңламаган да инде...

Мәскәүдә, ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршындагы югары комсомол мәктәбендә (ВКШ) укыган көннәр үзе бер мәктәп булган икән. Латвиянең «Пионерис» газетасы, «Драугс» журналы, Казакъстанның – «Балдырган», Үзбәкстанның – «Гулхан», Эстония, Грузия, Украина, Азәрбайҗаннарның «Пионер», Татарстанның «Ялкын», Чуашстанның «Хатер пул» журналлары редакторлары бергә лекцияләрдә утырабыз... Демократик яшьләр оешмалары, пионер матбугатының оештыру функцияләре, балалар журналистикасында үзгәртеп кору дигән темаларга сөйләшәбез. Кайбер фикерләр, кагыйдә булып, күңелгә кереп калган: «Вожатый образы укытучыныкыннан мөһимрәк», «Тормышыбыздагы реформаны иң элек балалар күңелендә үткәрергә кирәк», «Балалар журналисты – үзе бер профессия»... «Комсомольская правда», «Пионерская правда», «Учительская газета», «Вожатый», «Пионер» журналлары редакцияләрендә мастер-класслар алабыз. Һәм ул аралашулар, тәҗрибә уртаклашулар, кайткач, үз эшләребездә чагыла.

...Шушы истәлекләрне барлап утырганда, сөенечле хәбәр килеп иреште: балалар оешмасының олы юбилее көннәрендә совет пионериясенең аналогы булырлык оешманы россиякүләм торгызу кирәклеге турында инде җитди уйланалар икән! Кремльдә Россиягә пионер оешмасын кайтаруны хуплаганнар! Үсеп килүче буынны патриотизм, Ватанга мәхәббәт рухында тәрбияләү, аларны иҗтимагый-сәяси темаларга дискуссияләрдә катнашырлык итеп әзерләү, Россия дәүләтчелеге символларын белүләренә ирешү, иптәшләренә, өлкәннәргә хөрмәт белән карау, мохтаҗларга ярдәм итү, гел алдынгылар сафында булырга омтылу кебек сыйфатларга ия чын гражданнар үстерү максатын күздә тота әлеге оешма. Илнең 85 регионыннан меңләгән укучы бу көннәрдә Мәскәүгә, Кремль янәшәсендәге Гостиный дворга зур слетка җыела. Әлеге зур чара Россия Президенты Аппараты карамагында үткәреләчәк. Делегатлар «Бөтенсоюз пионер оешмасына – 100 ел» маркасын мөһерләү тантанасында катнашачак.

Нәкъ безнең пионер оешмасындагыча бай энергетикалы, быргылы-барабанлы, романтик рухтагы бәйрәм булыр дип өметләник! Нәкъ безнең җырдагыча булсын:

Һәрвакыт уяумы, әзерме?
Чакыра пионер быргысы!

Эльмира ЗАКИРОВА

Үземдә сакланган бу фото автографлар белән чуарлануның да үзенә күрә кызыклы тарихы бар. Казанга атаклы кино артистлары килгән иде. Дус кызым Камәрия белән Спорт сараена шул очрашуга киттек. Кемнәр генә юк! Вицин, Моргунов, Инна Макарова... Атаклы комментатор Николай Озеров... Автограф аласы килә! Ә сумкамда фотолар гына иде. Николай Озеровка, Георгий Вицинга, «Крокодил Гена»ны җырлаган Владимир Феропонтовка фотомны сузып, автографлар алам.

ҺӘРВАКЫТ ӘЗЕРМЕ?

vk.com

Россиядә пионериягә охшаш хәрәкәт булдырырга телиләр. Бу идеяне Россия Президенты Владимир Путин да хуплаган. Пионерияне кайтарырга кирәкме? «ВТ» шул хакта сорашты.

Айдар АКМАЛОВ, «Талантларның ачык университеты» оешмасының башкарма директоры:
– Кеше бүгенгесен дә, киләчәген дә билгеле бер образлар аша күзаллый. Пионерия дә – шундый образларның берсе. Минемчә, безгә бүген мондый хәрәкәт кирәк. Әйе, бездә балаларның «сусавын» басарлык, аларны кызыксындырырлык юнәлешләр бар. Әйтик, без эшли торган яшьләр экология белән кызыксына, туган авыллары, шәһәрләренең табигатен кайгырта. Ләкин пионерия олысын да, кечесен дә билгеле бер идея-кыйммәтләр янында берләштерә ала торган көчкә ия.

Гомумән, бүген яшьләрне үзебез җәлеп итмәсәк, алар бик үк яхшы булмаган оешмалар белән дуслашырга мөмкин. Ә кечкенәдән үк үз яшьтәшләре арасында ниндидер бер күмәк эш белән мәш килсәләр, бу, әлбәттә, яхшы.

Мәсьәләнең тагын бер ягы бар бит әле. Әйткәнемчә, бүген балалар өчен дә, әти-әниләр өчен дә сайлау мөмкинлеге зур. Оешма-хәрәкәтләрнең күп булуы аларның башын бутарга да мөмкин. Пионериягә охшаш хәрәкәт барлыкка килеп, үз баласының аңа кушылуын күргән әти-әниләр тынычрак булыр иде, миңа калса.

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ, балалар язучысы, журналист:
– Аның кирәк икәнлеге бәхәссез. Минем белән күпләр килешер: бүген кыйбла юк. Бигрәк тә балалар өчен. Безнең буын пионер булган вакытларын бик сагынып искә ала. Игътибар иткән булсагыз, социаль челтәрләрдә дә бу турыда шактый сөйләшәләр, язалар. Заман балалары пионериянең нәрсә икәнен дә, аның әһәмиятен дә белми. Аларга моны аңлатырга иде. Ләкин сиксәненче еллардан соң күпме сулар аккан, җәмгыять бик үзгәргән. Без бүген тизләнеш заманында яшибез. Хәзер инде элеккеге пионерияне ничек бар, шулай кайтара алмабыз. Аны оештырган очракта та, яңалыклар кертергә, бүгенге заманга туры китереп үзгәртергә кирәк. Аның тискәре яклары ул чакта ук булмады түгел. Озакка сузылган җыеннар, хисаплар, партия турында сөйләүләр. Боларын, билгеле, төшереп калдырырга, ә файдалы, практик якларын кулланырга кирәк дип уйлыйм.

Эльмира КАМАЛИЕВА, өч бала әнисе, блогер:
– Без пионерлар булырга өлгермәдек, ләкин әнинең бу турыда сөйләгәннәрен яхшы хәтерлим. Алар бөтенләй башка мохиттә үскән, барысы да бер үк кагыйдәләргә буйсынган, билгеләнгән кысалардан чыкмаган. Мәрхәмәтлелек, эш сөючәнлек кебек күркәм сыйфатлар өстенлек иткән ул чакларда. Хәзер хәл башкачарак. Үзебезнең балалардан чыгып әйтәм: алар эшләргә яратмый. «Улым-кызым, булыш әле миңа», – дип, исләренә төшереп торырга кирәк. Без, әти-әниләр үзебез дә, иң мөһиме – укысыннар, яхшы кеше булсыннар, дия-дия, күп нәрсәгә күз йомабыз. Пионериягә хас булган кагыйдәләр кире кайтса, һич югы эш сөяргә өйрәнерләр иде. Аннан соң, бүгенге балалар агрессив, үз эчләренә бикләнгәннәре дә җитәрлек. Компьютер, телефоннан чыга алмыйлар. Аларны берләштереп, бер-берсе белән аралаштырырга иде. Рухи яклары аксый, олыны – олы, кечене кече итә белү дигән нәрсә юкка чыгып бара. Ниндидер күмәк эш белән кызыксындыра ала торган, өлкәннәрне, укытучыларны хөрмәт итәргә өйрәтә торган ниндидер бер система җитми бүген.

Ринат ХӘЙРУЛЛИН, Мамадыш районының Урта Кирмән мәктәбе укытучысы:
– Элеккеге пионерия ул халәтендә бүген яши алмый инде. Алар бит тоталитар режим оешмалары булган. Бүген демократик җәмгыять төзергә дип йөрибез икән, үз фикере булган шәхес тәрбияләргә кирәк. Андыйлар: «Һәрвакыт әзер!» – дип тормый. Бүген балаларны кечкенәдән үк үз-үзен тәэмин итәрлек акча эшләргә, финанс яктан грамоталы булырга өйрәтергә кирәк. Бүген кыйммәтләр башка, дип әйтәсем килә. Мәктәпләрдә эшли торган варислар оешмасы да күбрәк формаль әйбергә әйләнеп бара. Көтелгән нәтиҗәләрне бирә, димәс идем.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Иң оста коръәнхафиз ачыкланачак

Казанда Халыкара изге Коръән уку бәйгесе башланды. Ул 20 майга кадәр дәвам итәчәк. Анда чит илдән – 30, Россиядән 20 кеше катнаша.

Бәйге дин кардәшләребезне Коръән уку традицияләренә җәлеп итү, коръәнхафизлардан иң яхшы укучыларны ачыклау максатыннан, Татарстан Президенты ярдәмендә үткәрелә. Аңа Евразиянең һәм Африканың 25 иленнән 70тән артык гариза килгән булган. Россиядән Дагыстан, Чечня, Татарстан, Башкортстан, Кырым республикалары вәкилләре катнаша.

Катнашучыларның Коръән уку осталыгын Берләшкән Гарәп Әмирлекләре дәүләт башлыгының Коръән буенча комитет җитәкчесе, шәех Мәэмүн Шәәбән Хәлил әр-Рави рәислегендәге халыкара хөкемдарлар коллегиясе бәяләячәк. Бәйге нәтиҗәләре буенча ир-атлар арасыннан 3 һәм хатын-кызлардан 3 җиңүчене сайлап алачаклар.

– Казан быел Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы статусына ия булды. Егермедән артык илдән килгән катнашучыларны кабул итү бик шатлыклы. Бу бәйге белән без «Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы» программасы кысасында халыкара чараларны башлап җибәрәбез, – диде Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин әйтүенчә, әлеге бәйге Россиядә беренче тапкыр уза. Жюри әгъзалары катнашучыларның Коръән укуының дөреслегенә һәм аны яттан белүенә караячак.

– Бу – безнең өчен зур һәм бик мөһим чара. Ул, беренче чиратта, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган. Коръән – мөселманнарның белем алу һәм рухи яктан баюының төп чыганагы, Аллаһы Тәгаләнең олы бүләге. Әлеге бәйге мөселманнар тормышында Коръәннең мөһимлеген ассызыклау, аларның Коръән уку сәләтләрен камилләштерү өчен оештырылды, – дип сөйләде мөфти.

Ләйсән САФИНА

1100 Болгар 922 2022

1100 еллык тарих

Тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз ХУҖИН ярдәме белән 1100 ел элек Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителү уңаеннан тарихи язмалар циклын дәвам итәбез. Болгар шәһәрләрендә озак еллар казу эшләрен алып барган, ислам дине тарихын өйрәнүгә зур көч куйган галимгә шушы уңайдан сорауларыгызны да җиткерә аласыз.

Караңгылык диңгезе янындагы ил

Идел Болгары – Урта гасыр мөселман цивилизациясе дәүләтләре чылбырында Хәлифәт тарафыннан рәсми рәвештә танылган буыннарның берсе. Аның икенче исеме дә бар – «Караңгылык диңгезе янындагы ил» («страна у Моря Мрака»). Болгар иле Евразия кыйтгасының көньяк поясын биләп торган мөселман дөньясындагы башка илләрдән бик еракта урнашкан. Бу исем шуңа ишарәли.

Идел Болгары зур дәүләт булган һәм хәзерге вакытта аларның нәсел дәвамчылары – Идел-Урал татарлары яши торган җирләрне биләп торган. Болгарларның археология истәлекләре (һәйкәлләре) нигездә Татарстан территориясендә, күрше Чуашстанның көньяк-көнчыгыш районнарында, Ульян, Самара, Пенза өлкәләрендә табылган. Аерым һәйкәлләр, шул исәптән шактый зур шәһәрлекләр Әстерхан өлкәсендә һәм Пермь краенда билгеле.

X гасырда бу җирләрдә «әс-сәкалибә» – «төньяк халыклары», ягъни болгарлар, барсиллар (берсула), эсегеллар, суварлар (савирлар), биләрләр һәм бәрәнҗәләр яшәгән, дип яза Ибн Фадлан. Гарәп тарихчылары исә: «Бу кабиләләр еш кына үзара сугышканнар, ә инде читтән берәр дошман килеп чыкса, берләшеп каршы торганнар», – дигән хәбәрләр калдырган. X йөз ахырында бердәм болгар халкы оеша, элеккеге кабилә исемнәре онытыла. Яңа дин, этносәяси процессларда үзенең берләштерүче ролен күрсәтеп, хакимият тирәсенә төрле кавемнәрне туплый ала.

Болгар халкы, башлыча авылларда яшәп, игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Халык икмәккә кытлык кичермәгән, моннан тыш, ашлык экспортның иң мөһим юнәлешләренең берсе булган. 1024 елда, Суздаль җирендә башланган ачлык вакытында, «болгарлар ашлык алып килделәр, һәм халык ачлыктан котылды» дип хәбәр итә рус елъязмачысы. Корылыклы 1229 елда болгарлар Идел буйлап бөтен рус шәһәрләренә ашлык ташып саткан һәм шуның белән зур ярдәм иткән.

Шәһәрләрдә һөнәрчелек үсә. Әйдәп баручы тармаклар – кара металлургия һәм металл эшкәртү – теләсә кайсы җәмгыятьнең икътисади көче, нигезе. Зәркәнчелек югары дәрәҗәгә ирешә. Зәркәнчеләр кыйммәтле металл эшкәртүнең катлаулы алымнарын белгәннәр. Алар, мәсәлән, хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясаганда бик нечкә алтын-көмеш җепләрдән үреп ясау (филигрань, скань) һәм бөртекләү (зернь) техникасын еш кулланганнар.

Болгар чүлмәкчеләренең уңышларын шәһәр һәм авыл җирлекләрендә археологлар тарафыннан ачылган югары җитештерүчән савыт-саба яндыру мичләре генә түгел, ә Көнчыгыш Европаның барлык төбәкләрендә бу савыт-сабаларның киң таралу факты да күрсәтә. Рус кенәзлекләрендәге шәһәрләрнең барысында да диярлек археологик казылмалардан яхшы сыйфатлы болгар керамикасы килеп чыга.

Болгар шәһәрләрендә пыяла әйберләр җитештерү XI гасырда башлана. Биләрдә уникаль һөнәрчелек комплексы – пыяла савытлар ясау остаханәсе ачыла. Әлеге һөнәрчелекнең элитар, бары тик эре шәһәрләрдәге җитештерү үзәкләрендә генә барлыкка килү мөмкинлеген ассызыклап үтәргә кирәк. Җитештерүнең бу төре ил икътисады үсешенең гомуми дәрәҗәсен дә ачык күрсәтеп тора.

Шулай ук күнчелек һөнәре дә үсеш ала. Көнчыгыш һәм Көнбатышның күп кенә илләрендә «болгари» дип аталган югары сортлы тире эшләнмәләре бик югары бәяләнгән.

Урта гасыр сәяхәтчеләре Идел Болгарстанын «шәһәрләр иле» дип атаганнар. Шул ук вакытта Болгар дәүләтенең «сәүдәгәрләр иле» дигән даны да булган. Әмма җитештерелгән продукция беренче чиратта халыкның үз ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә киткән, ягъни товар эчке базарга чыгарылган. Бер яктан, шәһәр белән авыл, икенче яктан, илнең төрле төбәкләре арасында җанлы сәүдә барган. Ә дәүләт казнасы башлыча тышкы сәүдә хисабына баеган.

Яңа дәүләт барлыкка килгәч, биргә дөньяның төрле почмакларыннан, бигрәк тә Шәрык илләреннән сәүдәгәрләр агыла башлый. Географларның энциклопедик язмаларында Болгар һәм аның халкы турында белешмәләр бирелә. Алай гына да түгел, Болгарны дөнья карталарында күрсәтәләр.

Идел Болгары геополитик яктан искиткеч уңай урында – Бөек Ефәк юлының төньяк тармагы булган Балтыйк – Идел юлы белән Чулман мех юлы кисешкән төбәктә калкып чыга. Болгар ханнары аның шушы өстенлегеннән бик оста файдаланалар: Идел буйлап кыйммәтле товарлар төяп килгән Шәрык сәүдәгәрләрен Болгарда туктаталар, тагын да төньяккарак җибәрмиләр; төньяктан, ягъни Новгород, Ладога якларыннан һәм Балтыйк, Скандинавия илләреннән килгән сәүдә корабларына исә Болгардан түбәнгә йөзәргә рөхсәт итмиләр. Шулай итеп, чит ил сәүдәгәрләре бер-берсе белән Болгар җирендә очрашырга мәҗбүр ителәләр. Ризасызлык күрсәтүче булмагандыр, чөнки тыныч һәм ике як өчен дә файдалы сәүдә өчен биредә бөтен шартлар тудырылган була.

Багдад илчелеге сәркатибе Әхмәд Ибн Фадлан язмаларына караганда, сәүдә корабларын Болгар ханы шәхсән үзе каршы ала торган була. Һәр товарның уннан бер өлешен ул, сәүдә практикасында кабул ителгән таможня кагыйдәләре буенча, дәүләт казнасына озатып барган. Аңлашыла ки, чит ил сәүдәгәрләреннән тотып калына торган әлеге салымның гомуми күләме сәүдәгәрләр санына һәм төяп килгән товар күләменә бәйле булган. Шул заман кешеләре, дәүләт казнасында тупланган байлыкның төп өлешен сәүдәдән кергән дисәтинә тәшкил итә, дип язганнар икән, димәк, Идел Болгарының Биләр, Сувар, Җүкәтау ише эре шәһәрләрендә җәен-көзен үткәрелә торган ярминкәләрнең ил тормышындагы роле зур булгандыр, дип уйларга кирәк.

Күренекле археолог һәм тарихчы академик Валентин Янин, нумизматика материалларына таянып: «Болгар VIII–IX гасырлардан ук Рус дәүләтенең сәүдә дөньясындагы көнчыгыш капкасы ролен үти башлый», – дип язган. Ягъни мәсәлән, русларга Шәрык илләреннән килгән товарлар Болгар аша үтеп кергән булып чыга. Бу фикер белән килешмичә булмый, әлбәттә, чөнки ул археология материаллары белән дә раслана.

Шул заман язучылары Ибн Рөстә, әл-Балхи, әл-Мәсгуди, әл-Мөкаддәси Болгардан Хәрәземгә һәм башка Шәрык илләренә чыгарыла торган товарларны санап китәләр. Бу исемлектә кыйммәтле җәнлек (кеш, тиен, сусар, ас, кызыл һәм кара төлке) һәм йорт хайваннары (кәҗә, сарык) тиреләре, яхшы сыйфатлы күн («болгари»), күннән һәм мехтан тегелгән әйберләр (бүрек, тун, кафтан, аяк киемнәре), бал, балавыз, урман чикләвеге, эре елга балыгы, каен агачы, ук очлары, кылыч, көбә күлмәк (кольчуга), сарык, мөгезле эре хайваннар, славян коллары ише товарлар бар. Болгардан чыккан экспорт товарларының исемлеген археологик материаллар нигезендә тагын да тулыландырырга мөмкин. Киев Русенең, соңрак рус кенәзлекләренең Киев, Новгород, Псков, Суздаль, Владимир, Рязань, Муром, Мәскәү, Рополч Залесский, Ростов Великий, Түбән Новгород, Городец һәм башка эреле-ваклы шәһәрләрендә, Белоруссия, Украина, Молдова җирләрендә, Балтыйк буе һәм Скандинавия илләрендә, Венгриядә болгар осталары тарафыннан ясалган югары сыйфатлы савыт-саба, барс һәм ат фигуралары рәвешендә ясалган бронза йозаклар, сөяктән эшләнгән камчы тоткалары, тараклар, алтын-көмеш бизәнү әйберләре һәм, әлбәттә инде, Болгарда сугылган көмеш акчалар табыла.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

Ничек яшисең, авыл?

«ВТ» архивыннан

Бәрәңге утыртмадыгызмы?

Бүген авылда яшәүче ике кеше очрашса, иң еш бирелә торган сорау бу. Шулай булмый хәле дә юк. Инде май аеның уртасы үтеп китте, әле күбебезнең җирләр шул килеш. Барыбызның дисәк, дөресрәк тә буласы, бик сирәкләр генә җирләрен эшкәртеп, утыртырга өлгерде. Алары да – үз мини-тракторлары, мотоблоклары булган кешеләр генә. Кемнәрдер, май ялларында балалар кайткан чакта эшләп калыйк дип, утыртырга ашыкты. Ашыкканнарын да белделәр, әмма өлкән яшьтәгеләр: «Үзебезнең генә көч җитми шул инде...» – диеште.

Тик тора-бара барыбызның да сабырлык бетә башлады. Күзләр бәрәңге бакчасында гына дисәк тә, ялгыш булмас. Әй, җәй озын әле, өлгерербез, дияр идең, безнең якларда фитофтора бик иртә төшә, күпме генә препаратлар белән эшкәртсәң дә, августта инде сабагы корый. Шуңа күрә август ахырында күпләр казып та ала.

Әлегә кадәр җирләрнең өлгергәнен көтәбез. Тик... бәрәңге бакчаларына ник бер чүп үлән чыксын! Туфрак өлгерүнең беренче билгесе шушы лабаса. Көрәк белән чыгып казып караучылар да бар. Алар да «өлгермәгән әле» дип пичәт куя... Агрономнар, бәрәңге үстерү белән шөгыльләнүчеләр исә ашыкмаска куша. Җылы туфракка утырткан бәрәңге күпкә тизрәк тишелеп чыга, май башында утыртканнардан алда да чыгачак әле, диләр. Каен яфрагы өч тиен акча кадәр булгач, бәрәңге утырту өчен иң кулай вакыт, дигән сынамыш бар иде. Әмма ул срок та үтеп бара, ышыграк урында яфраклар инде шактый матур булып күзгә күренә. Кемнәрдер, шомырт чәчәк атканда утыртсаң, бәрәңге өчен иң шәбе, ди... Инде алар да чәчәккә бөреләнгән. Бәлки, алар чәчәк атып бетергәнче, җирләр өлгереп җитәр.

Синоптиклар исә көн саен әле яңгыр, әле салкын, әле давыл-бозяшен вәгъдә итә. Болары да җир эшкәртергә тәвәккәллим дигән кешене туктатып кала. Болай да ярым-йорты өлгергән җирне эшкәрткәннән соң яңгыр явып китсә, ул тагын «утырачак»... Бәрәңге утырту өчен кабат эшкәртергә туры килмәгәе... Тыгызланган җиргә бәрәңге утыртсаң, рәт араларын эшкәртәм димә...

Авылда бүгенгә кадәр 4–5 кеше бәрәңге утыртса, соңгы көннәрдә ике-өч кеше җир эшкәртә башлады. Ә сала халкының гадәте шундый: берәү эшли башлаган икән, күршесе аннан калышмый инде. Өстәвенә авыл халкы утыртып бетергәч кенә бәрәңгегә керешә торган «Татарстан» хуҗалыгының да «икенче икмәк» басуларында берничә көн инде эш гөрли.

Тәвәккәлләрбез, ахры...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Бер генә басасы

Уңайлы, заманча, үзебезнеке. Журналистлар берлегендә TatTVR кушымтасын тәкъдим иттеләр. Нәрсә ул? Ни өчен кирәк?

TatTVR ул – Татарстанның теле- һәм радиоканалларын берләштерә торган SMART (интернеты булган) телевизорлар, Android (Google Play) һәм IOS (Apple Store) өчен махсус бушлай кушымта. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев сүзләренчә, әлеге кушымтаны булдыру – зур вакыйга.

– Безнең өчен әлеге кушымта зур әһәмияткә ия. Журналистлар берлеге тәкъдиме белән башланып киткән эшнең, ниһаять, нәтиҗәсен күрәбез. Бүген каналларны санап бетерерлек түгел. TatTVRны без үзебезнең телерадиоканаллар шушы күптөрлелектә югалып калмасын өчен булдырдык. Хәзер бит күпләр SMART телевизорларга күчә, мобиль кушымталар да популяр, – диде ул.

Бар да бер урында. TatTVRның төп үзенчәлеге һәм иң уңай ягы шулдыр, мөгаен. Бүген әлеге кушымта аша «Татарстан – Яңа Гасыр», «Эфир», «Татарстан – 24», «Мәйдан», «Шаян ТВ» телеканалларын карарга, «Болгар радиосы», «Тәртип FM», «Китап FM», «Күңел радиосы», «Искатель FM» радиоларын тыңларга мөмкин. Туры эфирда гына түгел, кушымтада телерадиоканалларның бай архивлары да сакланачак. Ягъни күңелегезгә хуш килгән тапшыруны үзегезгә уңайлы вакытта тыңлау һәм карау мөмкинлеге бар.

– Әлеге проект Татарстан Президенты ярдәме белән тормышка ашырылды. Архив та, каналлар да тулыландырылачак, алда безне зур эшләр көтә. TatTVRны Татарстанның телерадиоканалларын интернетта саклый ала торган төп платформага әйләндерәсе иде, – диде Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов.

Кушымтаны SMART телевизорга, Android һәм IOSка йөкләтү буенча киңәшләрне «таттвр.рф» адресы буенча кереп карарга мөмкин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Автор фотосы

ДОГАЧЫЛАР КИРӘК

Үзем күрдем

Апас районының Коштавыл авылында, ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан, балаларга дин сабаклары укырга башлаганнар. Сабыйлар һәр атнаның якшәмбесендә мәдәният йортында догалар өйрәнгән, дини-дөньяви вәгазьләр тыңлаган. Шушы көннәрдә ике ай белем алган балаларга иганәче авылдашлары бәйрәм ясады.

– Казаннан якташларыбыз кайтып, балалар догалар укырга өйрәнсен өчен берәр түгәрәк оештырып булмасмы, диделәр. Бик теләп риза булдык. Мәчетебездә ирләр белем алгач, сабыйларны мәдәният йортына җыярга булдык. Авылдашыбыз Гөлназ Латыйпова балаларга дин сабаклары бирде, – ди клуб мөдире Тәскирә Хафизова.

Укучыларны кызыксындыру өчен чәй табыны әзерләп торганнар. Тәм-томнар да өләшкәннәр. Дәресләргә башта 7 бала йөргән булса, соңыннан аларның саны 12гә тулган.

Балалар да, аларның әти-әниләре дә авылдашлары – «Апас» якташлык җәмгыяте әгъзасы Наил Галиуллин белән Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы Рәшит Байбиковка рәхмәт укый. Сәхнәгә чыгып, сүрәләр укыган һәр балага акчалата бүләк тә бирде иганәчеләр.

– Максатыбыз – авылыбызны яшәтү. Дога белгән баладан начарлык көтмисең. Аның күңелендә игелек була, – ди Наил Галиуллин. – Мөмкинлегең булса, чаралар да уздырасың, укулар да оештырасың. Әгәр анда йөрүче, килүче булмаса нишләрсең? Укуга йөргән балаларга рәхмәт. Бисмилласын әйтә белүе дә ни тора. Бу балалар булдырган әле. Мин «Әлхәм» сүрәсен алты ай ятлаган идем.

Мондый фикерне 20 ел авыл имамы булып торучы Ислам Гыймадиев та куәтләде. Аның бик тә авылдашларын дингә тартасы килә.

– Элек безнең авылда ике мәхәллә булган. Аның берсен, сүтеп, клубка әйләндергәннәр, икенчесе янып киткән. Бүген инде бер мәчетебез бар. Йөрүчеләр күп. Мин эшләгән вакытта мәчетебездә бары тик бер генә җомга намазы укылмыйча калды. Анысы да пандемиягә бәйле иде, – ди ул. – Элек без кечкенә вакытта хатын-кызлар дини иде. Әбиләрдән өйрәнеп үстек. Ә хәзерге дәү әниләрнең үзләренә дога өйрәтеп булмый. Мәчетебезгә килеп, гыйлем алу мөмкинлеге дә бар. Әмма күпләр телевизор кабызып, фильм карауны сайлый. Дингә килгәнсең икән – гайбәт ярамый, киемне үзгәртергә кирәк. Намазлар укыйсы була. Замана хатын-кызы шушы эшләрдән куркадыр инде.

Ислам хәзрәт әйтүенчә, балага тәрбияне әнидән дә яхшы бирүче булмаячак. Дәресләрдә өйрәнгән дога сүрәләрен өйдә кабатламаса, бала аны оныта, ди ул:

– Яшьләр уйлансын иде. Бик җиңел яшибез. Күпләр зиратларга барып җыештыруны, әрвахларга дога кылуны да онытты. Без бу эшләрне балабызга күрсәтеп эшләргә тиеш. Килер бер көн, каберләребез өстендә дога укучы булмас бит. Шуңа доганы кечкенәдән өйрәтергә кирәк.

Балаларга белем биргән Гөлназ Латыйпова авылдашларына үтемле вәгазьләр сөйләде. Укучылар ике ай эчендә күп кенә сүрәләр өйрәнгәннәр, диндә нәрсә тыелган, нәрсә ярый кебек сорауларга җавап тапканнар. «Әз генә вакыт эчендә инде кул күтәреп дога укый белүләре – зур эш», – ди Гөлназ абыстай.

Сабыйларны сөендерүгә өлешен керткән тагын бер иганәче Рәшит Байбиков авылдашларына диспансеризация дә үткәргән.

– Туган авылдан да кадерле җир юк. Өебез буш торса да, ял җиткән саен, күңел авылга тарта. Монда кайтып, яшәргә көч алып китәм. Авылыбыз кешеләре сөенеп торсын өчен берни дә жәл түгел. Кулдан килгәнне эшләргә тырышабыз, – ди ул. – Авыл яшәсен иде. Мәчетебез ишеге ябылмасын. Зиратны да чиста тотыйк. Күлләребез күп, аларны карыйк. Бергәләп эшләгәндә, барысын да башкарып чыгарбыз.

Коштавылда яшәүче эшмәкәр Гөлсинә Галиуллина да сабыйларны сөендерергә үзеннән зур өлеш керткән. Моннан 25 ел элек шәһәрдән авылына күченеп кайта ул.

– Мине кендек каным тамган җир тартып кайтарды. Монда рәхәтләнеп яшим. Бәйрәмнәргә ярдәм сорасалар, бик теләп булышам. Бирәсе рәхәт. Динебез дә гомерне игелектә уздырырга куша бит, – ди.

Бәйрәмгә килгән халык үз проблемасын әйтеп калырга ашыкты. Коштавылга юл кирәк, клублары искергән! Апас районы мәдәният бүлеге җитәкчесе Рөстәм Мингазиев озакламый яңа клуб булачак дип вәгъдә бирде. Юл проблемасын хәл итүне сорап, Президентка авылдашлар исеменнән хат тапшырганнар.

– Зур эшләрне дәүләт ярдәменнән башка эшләп булмый, калганын үзебез тырышабыз инде. Авылны бик яратам, бер дә бетерәсе килми. Авыл бетмәү бездән тора. Һәрберебез үзеннән кечкенә генә өлеш кертсә, яши әле ул, – ди Наил абый Галиуллин.

Бәйрәмгә кайткан Рузия Садретдинова Наил абыйны мактап телгә алды.

– Аның күңелендә – игелек кенә. Бөтен кешегә ярдәм кулы сузарга тырыша ул. Авылның киләчәге барга сөенеп торабыз, – диде.

Коштавылда яшәүчеләр өчен бу очрашу бер бәйрәмгә әйләнде. Алар янына Татарстанның халык артисты ИлСаф белән җырчы Айсылу Габдинова да кайткан иде.

– Читтә яшәүче авылдашларыбыз гел бәйрәм ясап тора. Нинди генә гозерең төшмәсен, кире бормый алар. Ничек тә авылыбыз яшәсен дип тырышалар. Без аларга бик рәхмәтле. Бу юлы бик саваплы эш башлап җибәрделәр. Балаларны дингә тарту, күңелләренә иман орлыгы салудан да зур эш юк инде ул, – ди шушы авылда яшәүче Рузилә Фәйзуллина.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

30 ЕЛ БАЛЫК ТОТУЧЫ ФЛЕРА ШӘЙМӘРДАНОВА:

«МИҢА МАТУР КИЕМ ТҮГЕЛ, БАЛЫК МӨҺИМ»

Шөгыль

Зәй районының Әхмәт авылында яшәүче Флера апа Шәймәрданова көн дә балыкка йөри. Аны авылда «балыкчы килен» дип йөртәләр. Ире Раиф абыйга да үз чирен йоктырган ул. Хатынының: «Әйдә балыкка», – дигән сүзе җитә аңа. Көне буе бер балык эләкмәсә дә, исләре китми.

Без барганда, Шәймәрдановларның тоткан балыкларын кыздырган чагы иде. Табышы әллә ни зур булмаса да, ир белән хатынга төшке ашка җиткән.

– Су буена гел төшәсе килеп тора. Балыгына да кызыгып түгел, җанга рәхәтлек алу өчен. Хатын-кызның балыкка йөрүен гадәти хәл кебек кабул итәм. Утыз ел буе йөрим инде. Шунысы кызык: бер дә туйдырмый. Кемгәдер матур кием, театр-концертка барып күңел ачу кирәк, ә миңа – балык. Мин фәкать кармакка гына тотам. Бер урында сәгатьләр буе тып-тын утыра алам. Сабырлыгым җитә. Ирем, бөтен балыкны тотып бетерәсең бит инде, дип шаярта. Ул бер урыннан икенчесенә йөреп тота. Кыш көне бәкедән дә тоткан бар. Тик салкында илһамланып тотып булмый. Бер балык эләкмәсә дә, вакыт әрәм булды, дип уфтанган юк, – ди 59 яшьлек Флера ханым.

Эш күп дип торсаң, өйдән мәңге чыгып китеп булмый. Һәр авыл кешесенеке кебек Шәймәрдановларның да эше җитәрлек. Мал-туарын да асрыйлар, тавык-чебешләре, үрдәкләре дә бар. Авыл халкы: «Сез ни арада барысына да җитешәсез соң?» – дип аптырый икән. Иртүк торып, бер кат өйдәгесен карыйлар да бергәләшеп су буена китәләр. Дөньяларын онытып, көн буе кайтып кермәгән чаклары да булгалый. Мавыгудан бары көннең бозылып китүе, яңгыр гына аера.

Флера апа – Югары Нәлем авылыныкы. Чаллыда яшәп, ике кыз тәрбияләгәннәр. Тик кинәт кенә ире вафат булган. Раиф абый да тормыш иптәшен югалткан. Канатлары каерылган ике яр бер-берсен табышып, 9 ел матур гомер кичерәләр. Җәй җитсә – җиләккә, көзен гөмбәгә йөриләр. Балык инде, әйткәнемчә, беренче урында. Кызлары, оныклары да Флера апа кебек балык тотарга ярата икән.

«Авылларда инешләр сай бит хәзер. Балык бармы соң?» – дип сорыйм хуҗабикәдән.

– Бәртәс, алабуга, кәрәкә, кызыл канатлар... Эре балык юк инде. Минем өчен инешнең тирәнлеге мөһим түгел. Кечкенә вакытта абыйларга ияреп, күлмәк белән сөзеп, балык тота идем. Тал чыбыгына каурыйдан калкавыч (Флера апа аны тәләкә ди) куеп, кармак ясый идек. Менә шул еллардан ук елга буена аерым мәхәббәт минем. Эресен тотар өчен Минзәлә елгасына барган идек. Унлап чуртан эләкте. Берсе дүрт кило иде. Ләкин алай еракка барып булмый шул, – ди ул.

Гадәттә, балыкчылар төрле ырым-шырымнарга ышана. Тик Флера апа моңа игътибар итми. Балык тынычлыкны ярата, шауласаң, ул су төбенә китәчәк. Менә шуны яхшы белә. Шуңа күрә иң хәерлесе – сөйләшмәү. Кемдер җим урынына кукуруз, борчак, кибет җимен кулланса, Флера апа суалчанга каптыра. Яңгырдан соң шәп чиртәләр икән. Балыкны тоту – бер нәрсә, әмма энәдән аеру авыр. «Ачуланмагыз инде мине, дип кармактан салдырам. Тотасы да килә, кызгандыра да», – ди балыкчы.

Сәрия МИФТАХОВА

Зөлфия Хәлиуллина

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 268

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+